РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

06 июня 2024 года № 82-1

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, 2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр билгеләү максатларында, Совет Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Мөкерле  авыл җирлеге

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча недоимканы, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану өчен түбәндәге өстәмә нигезләрне билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирасны кабул итмәгән очракта, мирас ачылган көннән алып бер ел эчендә вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар карамагындагы бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамлангач, физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 августындагы 72-1 номерлы «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль

районының  Мөкерле

авыл җирлеге башлыгы С.Н. Тюплина